

10 февральдә Мордовия Дәүләт Жыелышы (Председатель Государственного Собрания) рәисе Владимир Чибиркин, Мордовия Хокүмәте (Председатель Правительства РМ) рәисе Дмитрий Поздняков, РМ буенча Баш федераль инспектор (Главный федеральный инспектор по РМ) Михаил Сезганов, Мордовия прокуроры Сергей Лапин, хокук саклау структуралары житәкчеләре һәм вәкилләре катнашында Мордовиянен гомуми юрисдикция судларынын 2022 елдагы эшенә йомгак ясау буенча кинәшмә узды. РМ Югары Суды рәисе Валерий Кияйкин докладында билгеләп үткәнчә, гомуми юрисдикция судлары һәм жәмәгать судьялары тарафыннан узган ел 150 менгә якын граждан, административ эш һәм материаллар, административ хокук бозулар турында 38 менгә якын эш, 3320 жинаять эше каралган.

Судлар закон чыгару һәм башкарма хакимият белән актив катнашалар. Бу уртак эшкә унай бәяне Мордовия Дәүләт Жыены рәисе бирде. Владимир Чибиркин суд органнары һәм тобәк парламенты хезмәттәшлегенен топ юнәлеше - жәмәгать судьялары эшчәнлеген тәэмин итү, дип искәртте. Әйтик, узган ел Дәүләт Жыелышы сессияләрендә 17 жәмәгать судьясы билгеләнгән (11 вәкаләтләр (полномочий) срогы чикләнмичә һәм 6 – срогы 3 елга).

2022нче елда Мордовия Дәүләт Жыелышы, республика Югары Суды белән берлектә, «Россия Федерациясе субъектларында жәмәгать судьяларынын гомуми саны һәм суд участоклары саны турында «Федераль законнын 1 статьясына үзгәреш кертү һәм Мордовиядә суд участоклары санын бер берәмлеккә (44тән 45кә кадәр) арттыру һәм бер жәмәгать судьясы вазыйфасын остәмә кертү олешендә» федераль закон проекты эшләнде. Шулай ук жәмәгатьчелек вәкилләрен Мордовия Республикасы Судьяларынын квалификация коллегиясенә билгеләү дә уздырыла.

«Суд жәмәгатьчелегенен игътибар үзәгендә гражданнарнын, бигрәк тә халыкнын аз якланган категорияләренен, шул исәптән пенсионерларнын, ятимнәрнен, инва-лидларнын хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре булырга тиеш. Бу аеруча бүген махсус хәрби операция ясауга бәйле. Республикада яшәүче һәр кеше профессиональ суд ярдәме һәм яклау алачагына ышанырга тиеш», - дип билгеләп үтте Владимир Чибиркин.

Традиция буенча йомгаклау кинәшмәсендә Мордовиянен судьялар корпусы вәкилләренә бүләкләр тапшырылды.

**Наилә НАСЫРОВА әзерләде**